**Татарстан Республикасы Азнакай район Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 365-48 «24» август 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2018 елның 19 апрелендәге 187-28 номерлы «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, Контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында " карары белән расланган ,үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә сайланулы органнары әгъзалары, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башлыгы урынбасары, депутатлар, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында Контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторы, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын айлык акчалата бүләк күләмен арттыру һәм җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторы, Азнакай муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (28.05.2018 ел №195-29, 28.12.2018 ел №230-33 карарлар редакциясендә)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 06 августындагы 658 номерлы «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында" карары нигезендә

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар итә:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2018 елның 19 апрелендәге 187-28 номерлы «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы

муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында " карары белән расланган , үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы Азнакай муниципаль районы башлыгы, Азнакай муниципаль районы башлыгы урынбасары, депутатлар, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары, контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторына айлык акчалата түләү күләмен 2020 елның 1 октябреннән 1,03 тапкыр арттырырга.

2. 2020 елның 1 октябреннән, Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2018 елның 19 апрелендәге 187-28 номерлы «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында " (Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 28.05.2018 ел №195-29, 28.12.2018 ел №230-33 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) карары белән билгеләнгән, алар биләгән муниципаль хезмәт вазыйфалары нигезендә Азнакай муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттырырга.

3. 2020 елның 1 октябреннән, Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2018 елның 19 апрелендәге 187-28 номерлы «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында " (28.05.2018 ел №195-29, 28.12.2018 ел №230-33 карарлар редакциясендә), җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторына, Азнакай муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә үзгәршләр кертергә:

3.1. 1.5 пунктта. «11 163,00» санын "11 498,00" санына алмаштырырга»;

3.2. 1 нче кушымтаны әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Азнакай район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләнә.

Рәис М. З. Шәйдуллин

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карарына кушымта
«____» __________ 20___ ел

Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторы, Азнакай муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында1 нче кушымта

Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль район башлыгы, депутатлар, Җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында Контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторына айлык акчалата түләү күләмнәре

| Муниципаль берәмлек халкы санынннан чыгып, хезмәт өчен түләү төркеме) | 4 нче төркем хезмәт хакы |
|---|---|
| Муниципаль берәмлек | Муниципаль район |
| Иң чик вазыйфаи оклад (сумнарда) | |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 31 966 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 28 767 |
| Депутатлар | 15 492 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары | 13 166 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 28 767 |
| Контроль-хисап палатасы аудиторы | 13 166 |